**Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларында укучы балалар өчен татар теленнән олимпиада биремнәренең ҖАВАПЛАРЫ**
**2025-2026 нчы уку елы**
**6 нчы сыйныф**

**Максималь балл – 57**

**I. ТЕСТ (20 балл)**

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| **3** | **2** | **4** | **1** | **3** | **2** | **3** | **3** | **4** | **3** |

**II. Теоретик бирем.**

Шигырьне укыгыз. Аерып бирелгән исемнәрнең тиешле кушымчаларын языгыз. Исемнең килеш белән төрләнеше турында белгәннәрегезне языгыз. (**10 балл**) **5+ 5**

Мин **бәхетне** кайдан алырмын,
Туган **йорттан** китсәм **гомергә**?
Таш булып мин җансыз калырмын,
Сүз югалыр минем **телемдә.**
Бер көн артык миңа мең **елдан,**
Айда түгел, туган илемдә! (*Н. Дәүли*)

Укучы исемнең килеш белән төрләнеше турында мәктәп программасы, дәреслекләрдә бирелгән материалны мөмкин кадәр тулы чагылдырган очракта, мисаллар белән дәлилләгәндә, биремгә иң югары балл **(5)** куела. Төгәлсезлекләрнең күләменә карап, баллар саны киметелә. Мәгълүмат бөтенләй булмаган очракта, укучыга 0 балл куела.

**III. Уйлагыз һәм җавапларны языгыз.**

Сүз ясалыш чылбырында төшеп калган сүзне языгыз. **(5 балл)**

Яшел – ___ **яшелчә** ___, яшелчәче
Өмет – ___ **өметсез** ___, өметсезлек
Аш –___ **ашла** ___, ашлама
Сабыр – ___ **сабырсыз** ____, сабырсызлык
Бүл –___ **бүлмә** ___, бүлмәдәш

**IV. Гамәли-иҗади бирем.**

11. Сүз һәм аның килеп чыгышы ягыннан төркемчәсен тәңгәлләштерегез, җавапны саннар белән языгыз. **(5 балл)**

| | |
|---|---|
| А) дизель | 1) рус алынмасы |
| Ә) салам | 2) төрки-татар сүзе |
| Б) абый | 3) фарсы алынмасы |
| В) мәдрәсә | 4) гарәп алынмасы |
| Г) җиһан | 5) Европа алынмасы |

**Җавап : 51243**

2. Шигырьне укыгыз һәм күп нокталар урынына тиешле хәрефләрне куегыз. **(2 балл) һәр төшеп калган хәреф – 0,5 балл**

Кызык сезгә, яшь балалар, кышкы кичтә!
Җылы өйдә утырасыз якын мичкә;
Утырасыз рәхәтләнеп, т**е**зелешеп,—
Шатлык сезгә, уңайсызлык килми **һ**ич тә.
Һичкайсыгыз таныш түгел хәсрәт берлә,
Утыргансыз матур гына, рәт-рәт берлә;
Кышкы кичнең оз**ы**нлыгын сизмисез дә
Ә**н**кәгезнең сөйләгәне әкият берлә. (*Г. Тукай*)

3. Шигырьдән антоним сүзләрне күчереп алыгыз, сүз төркемнәрен күрсәтегез. **(3 балл)**
**шатлык – хәсрәт. Исем сүз төркеменә карый**

5.*Берлә* сүзенең хәзерге татар телендәге сүзен языгыз. **(2 балл)**
**белән**

6. “Кышкы кич” темасына 8-9 җөмләдән торган инша языгыз. (**10 балл**)